| | |
|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

**Татарстан Республикасы Биектау районының Сосновка авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлегe сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында**

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Биектау районының Сосновка авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Биектау районының Сосновка авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2014 елның 24 октябрендәге ПУ-1003 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2014 ел, 30 декабрь
№ ПУ-1189